**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

ЧЕРЕМШАНСКИЙ

МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН

**СОВЕТ КАРАМЫШЕВСКОГО**

**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул. Школьная, д. 5, с. Карамышево, 423119

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ

РАЙОНЫ

**КАРМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Мәктэп урамы, 5 йорт, Кармыш авылы, 423119

тел./факс (84396) 4-22-23, email: .Karam.Cmn2@tatar.ru

---

№100 27.06.2023 ел

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Кармыш авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге Советының «Коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне һәм чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән өчен җәзаларны куллану тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 15 маендагы № 42 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт идарәсен камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 21 ноябрендәге № 329-ФЗ, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы № 25-ФЗ, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 13 июнендәге № 258-ФЗ Федераль законнар нигезендә Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге Советының 2013 елның 13 мартындагы № 88 карары белән расланган «Коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне һәм чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән өчен җәзаларны куллану тәртибе турында» нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5 пунктының 2 нче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау өчен җаваплы (җаваплы) җирле үзидарә органының кадрлар бүлеге (кадрлар хезмәте) яки «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ Федераль законның 13_4

статьясы нигезендә Россия Федерациясе Президенты хакимиятенең вәкаләтле бүлеге тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад».

2. Әлеге карарны рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Кармыш авыл җирлеге башлыгы урынбасары,

Совет рәисе урынбасары И.Х. Мөбирдин